**КАРАР**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫН ХӘЛ ИТҮ**

2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында
Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы
Гулкин авыл җирлегенең Гулкин торак пунктында

**18.11.2025** **№ 1**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 6 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлегендә халык җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлеге Гулкин торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертергә, моңа көндезге формада белем алучы студентлар, I төркем инвалидлар, ялгыз өлкән гражданнар, мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар һәм контракт буенча Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә юлланган.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (торак пункт эчендә юлларны вак таш белән сибү).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) 7 көн дәвамында (Гулкин авыл җирлеге Уставының 69 п.5 статьясы) кабул ителгән көннән.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Гулкин авыл җирлеге башлыгы ____________ (имза) С.Д. Инькова
(имза расшифровкасы)